**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17 нчейорт. Тел.3-13-44.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-13-44.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

________ № _____

**2023 елга Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясе составы турында**

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Гражданлык оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы территориясендә хәрби шартларда һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссиясен төзү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 11 июлендәге 473 номерлы карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районында хәрби конфликтлар һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халыкның исән калуын, әлеге оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе составын, 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру комиссиясе составы турында» 2022 елның 04 мартындагы ПГ-12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Л.Р.Зарипов

Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
__________ 2023 ел, №___
1 нче кушымта

Хәрби вакытта һәм гадәттән тыш хәлләрдә Актаныш муниципаль районы территориясендә оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру комиссияләре составы

| | |
|---|---|
| 1.Ильясов Р.А. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе - комиссия рәисе; |
| 2.Гарипов Р.И. | Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе урынбасары; |
| 3.Әнвәрова Д.М. | Татарстан Республикасы Актаныш районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - комиссия рәисе урынбасары; |
| 4.Мортазин И.М. | 103 нче янгын сүндерү бүлеге башлыгы - комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| 5.Мулюкова Р.И. | Татарстан Республикасы Актаныш район Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге башлыгы - комиссия секретаре. |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| 6.Хузахметова Г.Ф. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы - социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе (килешү буенча); |
| 7.Хәернасов Р.Ф. | Актаныш РУЭС баш инженеры - идарә, элемтә һәм хәбәр итү системаларының тотрыклылыгын арттыру буенча төркем җитәкчесе (килешү буенча) |
| 8. Рәхмәтуллин А.М. | «Актаныш автотранспорт хуҗалыгы» МУП директоры - транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе (килешү буенча); |
| 9.Әхмәтханов А.М. | «Коммунсервис-Актаныш» ҖЧҖ директоры - торак- |

| | |
|---|---|
| | коммуналь хуҗалык эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе (килешү буенча); |
| 10. Сәлимгәрәев Н.А. | Актаныш муниципаль районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы - агросәнәгать комплексы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе (килешү буенча). |